(Бишенче чакырыш)
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авыл җирлеге Советы
# КАРАРЫ

Сәпәй авылы № 13 «19» декабрь 2025 ел

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге №109 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (17.08.2015 №130, 29.10.2015 №12, 24.04.2018 №90, 13.11.2018 №111, 28.12.2018 №117, 26.06.2019 №136, 05.11.2019 №146, 17.03.2021 №20, 29.11.2024 №137 карарлар редакциясендә)**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында»2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Сәпәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге №109 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (17.08.2015 №130, 29.10.2015 №12, 24.04.2018 №90, 13.11.2018 №111, 28.12.2018 №117, 26.06.2019 №136, 05.11.2019 №146, 17.03.2021 №20, 29.11.2024 №137 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән объектлардан тыш, 2025-2027 елларга кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына 2 процент тәшкил итә»;

1.2. 2 пунктның 4.1 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo. tatarstan.ru

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Ф.Г.Галиева